**Республика Татарстан**
**Руководитель Исполнительного комитета Бухарайского сельского поселения Заинского муниципального района**
Ул. Новая, д. 4, с. Бухарай,
Заинский район, 423536

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Бохарай авыл җирлегенең башкарма комитеты җитәкчесе**
Яна урамы, 4нчейорт,
Бохарай авылы, Зәй районы,
423536

Телефон, факс 6-77-34. Электронный адрес: Buhar.zai@tatar.ru, сайт: www.Buhar.ucoz.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 3**

**КАРАР**
**02 февраль 2022 г.**

**«2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм җирләрне саклау муниципаль программасын раслау турында» 2021 елның 01 ноябрьдәге 13 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм җирләрне саклау муниципаль программасын раслау турында» 2021 елның 01 ноябрьдәге 13 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымтада 4 нче бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

4. Муниципаль программаның төп чаралары исемлеге

Муниципаль программа кысаларында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге территориясендә җирләрне саклауның һәм алардан файдаланунының нәтиҗәлелеген арттыру буенча түбәндәге чаралар планлаштырылган:

| N п\п | Чараның исеме | Финанслау чыганагы | Башкаручы | Башкару срогы | Җаваплы зат |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының җир законнары нормаларын гражданнар җыеннарында аңлату | Җирле бюджет: 2021 ел – 100 сум, 2022 ел – 100 сум, 2023 ел – 100 сум | Җирлек башкарма комитеты | 2021-2023 еллар | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 2. | Авыл хуҗалыгы җирләрен агачлар һәм куаклар, чүп үләннәре басып китүдән саклау һәм зарарлы организмнардан яклау чаралары үткәрү | Җирле бюджет: 2021 ел – 900 сум, 2022 ел – 900 сум, 2023 ел – 900 сум | Җирлек башкарма комитеты | 2021-2023 еллар | Башкарма комитет җитәкчесе |

2. Карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Е.В. Груздева